РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава Тумутукского
сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Тельмана, д.62 Б, Азнакаевский район,
с.Тумутук, 423316,
тел./факс (885592)34-3-42
E-mail: Tumut.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге
башлыгы

Тельман ур., 62 Б йорт, Азнакай районы,
Тымытык авылы, 423316
тел./факс (885592)34-3-42
E-mail: Tumut.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«27» октябрь 2025 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында“ 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елның 11 ноябрендә 10:00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгер торак пунктында, Совет ур., 27 йорт адресы буенча урнашкан Әгер авылының мәдәният йорты залында 2026 елда үзара салымны кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлегенең Әгер торак пунктында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

   “Сез, 2026 елда Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, 1 нче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
   -торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Җәлил, Совет, Тукай урамнары буйлап вак таш сатып алу, төяү, ташу, җәю)

*«РИЗА»* *"КАРШЫ"*

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

   - 2025 елның 27 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес тәэмин итергә: Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б йорт;

   -сайлау хокукына ия булган Әгер торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

   - гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

   - Әгер торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Әлеге карарны Тымытык авыл җирлегенең Әгер авылы, Совет ур., 27 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru., Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.Р.Мостафина